**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге**

422008, Әтнә муниципаль районы
Түбән Шашы авылы, Молодежная
урамы, 68
тел. 3-60-38, факс 3-60-38

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Кунгерское сельское**
**поселение**

422008, Атнинский муниципальный район
д.Нижние Шаши,ул.Молодежная,68
тел. 3-60-38, факс 3-60-38

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2025 ел. № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елнын 24 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенә керүче Күшәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенының 1 нче этабын үткәрү вакыты – 2025 елның 24 ноябре 10.00 сәгатькә ;

-гражданнар җыенының 2 нче этабын үткәрү вакыты – 2025 елның 24 ноябре 14.00 сәгатькә ;

- гражданнар җыенының 1 нче этабын үткәрү урыны – Күшәр авылы, Татарстан урамы,мәдәният йорты яны;

-гражданнар җыенының 2 нче этабын үткәрү урыны –Күшәр авылы, Комсомольская урамы, балалар уен мәйданчыгы яны;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Шашы авылы, Яшьләр урамы, 68 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Күшәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

-гражданнар җыены турында Күшәр торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Авыл территориясен төзекләндерү (үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту,эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, вак таш сатып алу транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү);
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зират территориясен чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

"РИЗА" "КАРШЫ"

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күшәр авылы, Тукай урамы 21 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И .